ЯКШӘМБЕ
11 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 34 (5834)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

МЕХАНИЗАТОР КАДРЛАР ХӘЗЕРЛӘҮНЕ ИГТИБАР ҮЗӘГЕНӘ!

Язгы чәчүне кыска срокта, югары сыйфатлы итеп үткәрүдә машина-трактор паркы хәл иткеч роль уйный. Бу зур һәм җаваплы бурычны уңышлы рәвештә хәл итүдә тракторларның вактында, яхшы итеп ремонтлануы, хәзерләнүе һәм аларның ягулык материаллары белән тәэмин ителүе белән бер рәттән, техниканы большевикларча үзләштергән механизатор кадрлар зур һәм мактаулы урын тоталар.

Авыл хуҗалыгын машиналаштыру темпы гаят зур һәм көчле адымнар белән үсә. Бу хәл безнең алдыбызга механизатор кадрлар хәзерләү мәсьәләсен кискен рәвештә көчәйтү бурычын бөтен тулылыгы белән куя. Бу бурыч 1940 нчы елга карата бездә ничек үтәлә соң? Дөресен әйтергә кирәк: бу бурыч хәзергә әле начар үтәлә. Конкрет фактлар һәм саннар моның шулай икәнлеген тулысынча раслыйлар.

Механизатор кадрлар хәзерләү буенча без быел Татарстанда барлыгы 9.715 кеше укытып чыгарырга тиешбез. 20 нче январьга булган мәглүматлар механизация кадрлары хәзерләү мәктәпләренә укучылар туплау планының бары 68,1 процентка гына үтәлгәнлеген күрсәтәләр. Аерым профильләр буенча эш тагын да күңелсезрәк. Газогенераторлы тракторлар өчен тракторчылар хәзерләү чиктән тыш начар тора, план бары 22,4 процент кына үтәлгән.

Механизатор кадрлар хәзерләүнең мондый зур өзеклектә булуының сәбәбе нәрсәдә соң? Моның сәбәбе республикабызның күп кенә МТС җитәкчеләренең, кадрлар хәзерләү курслары мәктәпләре директорларының бу эшкә җавапсыз, икенче дәрәҗәдәге эш дип карауларында, ТАССР Наркомземының, Татсовхозтрестның җитәкчелеге йомшак булуда һәм урыннардагы партия, совет һәм комсомол оешмаларының бу эшкә җитәрлек контроль булдырмауларында, оператив җитәкчелек итмәүләрендә.

Кадрлар хәзерләүгә кайбер МТС җитәкчеләренең бармак аша караганлыкларын түбәндәге фактлар бик ачык күрсәтәләр: Беренче Май МТС ы (директоры иптәш Юсупов), Акташ МТС ы (директоры иптәш Сурков), Кичү МТС ы (директоры иптәш Мамзяков) яңа маркалы тракторлар өчен кадрлар хәзерләү курсларына, комбайнчылар хәзерләү мәктәбенә соңгы көннәргә кадәр бер кеше дә җибәрмәгәннәр.

Бу хурлыклы хәл кичекмәстән бетерелергә тиеш.

Хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү мәсьәләсенә аеруча игтибар бирергә кирәк. Бу эшнең политик һәм оборона ягыннан әһәмияте гаят зур икәнлеге һәр кемгә аңлаешлы. Ләкин шулай булуга карамастан, республикабызда бу эш бик начар тора әле. Механизатор кадрлар хәзерләү мәктәпләрендә һәм курсларында укучы хатын-кызлар курсантларның гомуми санына караганда бары 13 процент кына тәшкил итәләр.

Узган елның язында СССР Верховный Советы депутатлары П. Ангелина һәм П. Ковардак, М. Мухортово, З. Бахолдина, К. Валчаева һәм башка иптәшләрнең инициативасы белән башланып, хатын-кыз яшьләрнең бөек хәрәкәтенә әверелгән эшнең—производстводан аермыйча хатын-кызлардан тракторчы кадрлар хәзерләү эше бездә гафу ителмәслек начар тора. Республикабызда бу мәсьәлә буенча алынган социалистик йөкләмә 1939 нчы елда МТС лар буенча бары 8 процент, совхозлар буенча 10,3 процент кына үтәлгән һәм хәзердә дә күпчелек районнарда бу эш таркау хәлдә тора. Мисальгә Чистай МТС ын һәм Чепья районындагы Дмитров исемендәге МТС ны алырга була. Бу МТС ларның беренчесендә бу көнгә хатын-кызлардан бер тракторчы да хәзерләнмәгән һәм хәзер дә бу өлкәдә ташбака адымы белән генә кыймылдыйлар, икенчесендә дә шундый ук хәл. Шуның өстенә Чепья районындагы кайбер колхозларның, конкрет алганда Буденный, Фрунзе исемендәге колхозларның һәм „Кызыл Юл“ колхозының председательләре тракторчылар хәзерләү курсларына укырга барырга теләүче хатын-кызларны нигезсез төрле сәбәпләр сылтавы белән җибәрмәгәннәр. Шунысы гаҗәп, бу фактлар МТС һәм район җитәкчеләренә билгеле булса да, алар турында бер нинди чара да күрелми. Хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү эшенең торышы болай начар булуын, барыннан да элек, күп кенә МТС, совхоз җитәкчеләренең, колхоз правлениеләренең, комсомол оешмаларының хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү мәсьәләсенә кирәгенчә политик бәя бирмәүләре, Татнаркомземның, Татсовхозтрестның һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетының бу бөек эшкә көндәлек җитәкчелек итмәүләре белән генә аңлатырга мөмкин.

Хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләүгә мондый җавапсыз, гамсез караш, һич шиксез, бетерелергә тиеш. Дөрес, республикабызда бу эшне яхшы гына итеп оештырган аерым МТС лар һәм совхозлар да юк түгел. Алар бар. Тымытык районының Вахитов исемендәге совхозында производстводан аерылмыйча 22 хатын-кыз тракторчы итеп хәзерләнгән. Тымытык МТС ында 56, Чалпы МТС ында 45 хатын-кыз курсларда укыйлар. Ләкин эшне шулай итеп оештыручыларның тәҗрибәләре Татнаркомзем, Совхозтрест һәм ВЛКСМ Өлкә Комитеты тарафыннан бөтенләй диярлек популярлаштерелми. Хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү партиянең, комсомолның һәрбер оешмасы алдында, совет һәм җир органнары, МТС һәм совхоз җитәкчеләре алдында торган иң мактаулы мәсьәләләрнең, политик һәм оборона ягыннан зур әһәмияткә ия булган мәсьәләләрнең берсе икәнлеген һәрбер җитәкче ачык аңларга һәм бу өлкәдә булган барлык җитешсезлекләрне тиз арада бетерүгә ирешергә тиеш.

ВКП(б) район комитетлары МТС һәм совхоз җитәкчеләренең механизатор кадрлар хәзерләү өлкәсендәге эшләрен аеруча контроль астына алырга, райком бюросында аларның докладларын куярга һәм бу өлкәдә эшнең яхшы куелуына ирешергә тиешләр. Оештырылган курсларның нормаль эшләүләрен булдыру өчен кирәк булганнарның барсын да тәэмин итү партия, совет, комсомол оешмаларының иң җаваплы бурычларыннан берсе икәнлекне дә онытмаска кирәк. Бурыч: машина-трактор паркын яхшы хәзерлекле кадрлар белән тулысынча тәэмин итүдән гыйбарәт. Кадрлар хәзерләүдә булган үрнәк методларны бөтен урыннарда кулланганда һәм бу мәсьәлә тирәсенә совет җәмәгатчелеген туплаганда бу мөһим бурыч, һич шиксез, үтәлер.

БЕРЛИН ОПЕРАСЫ ТЕАТРЫНДА „ИВАН СУСАНИН“ ОПЕРАСЫ

БЕРЛИН, 8 февраль. (ТАСС). Берлиннең дәүләт опера театрында кичә беренче тапкыр Глинканың „Иван Сусанин“ операсы куелды. Бөек рус композиторының оркестр тарафыннан яхшы башкарылган музыкасы бөтен залда шатлыклы кул чабулар тудырды. Халык Иван Сусанин, Антонида һәм Ваня рольләрен башкарган артистларны чын күңелдән котлады. Театрда халык тулган иде. Билетлар спектакльдән берничә көн алдан сатылып беттеләр. Театр журналының махсус номерында рус композиторларыннан Глинканың, Даргомыжскийның, Мусоргскийның, Римский-Корсаковның, Бородинның һәм Балакиревның күрнекле әсәрләре турында мәкаләләр басылган. Шулай ук „Иван Сусанин“ операсының Москваның Зур Академия театры постановкасында аерым күренешләреннән алынган рәсемнәр дә урнаштырылган.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

9 нчы февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Карелия бугазында дошманның югалткан позицияләрен кире кайтарырга күп тапкыр маташулары алар өчен зур югалтулар белән кире кагылды.

Безнең авиация сугыш объектларына уңышлы сугыш хәрәкәтләре ясады.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 8 февраль. Германиянең информация бюросы түбәндәгеләрне тапшыра: „Саар фронтында артиллерия хәрәкәте гадәттәгедән җанлырак. Ул, дошман разведкасының көчәюе аркасында җанланды. Күп кенә участкыларда дошманның атакалары кире кагылды. Югары Рейн фронтында дошманның радио буенча пропаганда алып барырга маташуы пулемет уты белән туктатылды“.

ПАРИЖ, 9 февраль. Кичә көндез фронтның кайбер участкыларында патрульләр хәрәкәте булганлык хәбәр ителә. Төнлә бер нинди үзгәреш булмаган.

БЕРЛИН, 9 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәгеләрне хәбәр итә: „Форбах районында Германиянең сакчылык отряды белән дошманның шактый артыграк сандагы разведка часте арасында сугыш булды. Дошманның берничә солдаты плен алынды“.

БЕРЛИН, 8 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, сугыш башланганнан бирле союзникларның һәм нейтраль илләрнең сәүдә флоты барлыгы миллион ярым тонна чамасы авырлыктагы 409 пароходын югалткан. 31 нче январьга Германия сәүдә пароходчылыгы бөтенесе 237.000 тонна авырлыктагы 42 пароходын югалткан. Дошман һәм нейтраль илләр пароходчылыгының югалтулары бер ярым миллион тоннадан шактый артыграк, чөнки англичаннар үзләренең югалтуларының бер өлешен һәр вакыт яшерергә маташалар.

БЕРЛИН, 9 февраль. Информация бюросы, Франциянең балык тота торган коралланган пароходының Лиссабон тирәсендә Португалия пароходын тотканлыгын хәбәр итә. Ике немец пассажиры пароходтан алынып Франциягә алып кителгән.

НЬЮ-ЙОРК, 9 февраль. Рио-де-Жанейродан хәбәр итүләренә караганда, нейтралитет мәсьәләләре буенча пан-Америка комитеты Америка республикаларына сугышучы илләрнең һава начар булу яки ремонт ясау кирәк булу аркасында туктау урны эзләргә мәҗбүр булган көймәләреннән башка су асты көймәләрен үзләренең территориаль суларына кертмәскә тәкъдим итте. (ТАСС).

ТҮБӘНГЕ ПАЛАТАДА ЧЕМБЕРЛЕННЕҢ РЕЧЕ

ЛОНДОН, 9 февраль. (ТАСС). Кичә түбәнге палатада Англия хөкүмәтенең баш министре Чемберлен сугыш хәрәкәтләренә һәм гомуми политик хәлгә күзәтү ясап чираттагы речен сөйләде. Көнбатыш фронттагы хәлгә кагылып, ул, Европада каты салкыннар булу аркасында соңгы атналарда әһәмиятле бер нинди вакыйга дә булмаганлыкны белдерде. Чемберлен Англия—Франция верховный хәрби советының соңгы утырышына тукталды. Бу мәсьәлә буенча тулы белдерү ясамыйча һәм бу мәглүматларның дошман өчен файдалы булуы мөмкин дигән сылтау белән, Чемберлен Англия һәм Франция хөкүмәтләре арасында ныклы контакт барлыкны күрсәтеп үтте.

Чемберлен, Англия хөкүмәте тарафыннан Финляндиягә күрсәтелгән ярдәм „аның өчен бик кыйммәтле“ диде һәм Финляндиягә тагын да ярдәм күрсәтү өчен яңа адымнар ясалганлыкны белдерде.

Аннары Чемберлен Балкан Антантасы сессиясенең йомгакларына тукталды һәм күп кенә финанс һәм экономик мәсьәләләр буенча Англия—Греция арасында бара торган сөйләшүләрне искә алып үтте.

Англиянең сәүдә карабларына Германия авиациясенең һөҗүм ясавына тукталып, Чемберлен, 4 нче февральдә булган һөҗүм вактында Германиянең 3 самолеты бәреп төшерелгәнлекне һәм алардан тыш бер су асты көймәсенең батырылганлыгын белдерде. Чемберлен 3 нче февральдә булган һөҗүм вактында немецләрнең Англиянең сугыш карабларын саклап баручы кимендә 9 карабларын батырганлыклары турында Германия белдерүләрен юкка чыгарды.

ЛИТВАДА ПОЛЯК ЗАГОВОРЧЫЛАРЫ ОЕШМАСЫ

КАУНАС, 9 февраль. (ТАСС). Литва телеграф агентлыгы Вильнода поляк офицерларының заговорчылык оешмасы фаш ителүе белән үз сотрудникының эчке эшләр министре Скучас белән беседасын иглан итте.

Скучас болай дип белдергән:

„Безнең охрана органнарыбыз Вильнода үзара элемтәдә эшләгән 2 поляк оешмасын ачтылар. Аларның эше Литва дәүләтенә каршы юнәлдерелгән булган. Бу оешмаларның членнары кулга алындылар. Алар арасында Вильно өлкәсендә торучылар бары 17 процент кына. Калганнар исә барсы да монда элекке Польшаның башка өлкәләреннән, башлыча 1939 нчы елның көзендә килгәннәр. Тикшерү мәглүматлары ике оешманың да Польша җимерелгәннән соң ук көчле рәвештә оеша башлаганлыкларын күрсәтәләр.

Гомумән исә Вильно өлкәсендә тулы тәртип һәм тынычлык барлыкны күрсәтеп үтәргә тиешмен“.

КАУНАС, 9 февраль. (ТАСС). Вильнода поляк офицерларының беренче заговорчылык оешмасының эше буенча тикшерү тәмам булды. 13 кеше хәрби судка бирелә, 5 кеше концентрация лагерына ябылачак.

Болгариядә Англия агентының эше турында Германиянең информация бюросы

БЕРЛИН, 9 февраль. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Софиядән түбәндәгеләрне хәбәр итә: „Сугыш башланганнан бирле Болгариядә Англия пропагандасы тагын да көчәя.

Декабрь башында Англиянең чит ил эшләре министрлеге һәм разведкасы Англиянең Софиядәге миссиясенә Англиянең Милләтләр Лигасындагы элекке вәкиле, „Британия советы җитәкчесе лорд Ллойдның якын дусты майор Эйбрехем җибәрелгән иде. Аңа Балканда „культураны җәелдерү оешмасы“ төзү йөкләтелде. Бу оешма „Британия советы“ җитәкчелегендә булачак. Лорд Ллойд Болгариягә барып кайтканнан соң бу оешма Балкандагы башка дәүләтләрнең башкалаларында да үзенең филиалларын төзеде. Ул интеллигенциянең бөтен катлавын үзенә тартырга омтыла. „Британия советы“ның „Культура оешмасы“ составына промышленниклар, журналистлар, врачлар, отставкадагы офицерлар һәм ирекле профессиядәге кешеләр керәләр. Казыну һәм агитация эшләре алып бару өчен майор Эйбрехемгә шактый акча бирелгән. Майор Эйбрехемның икенче бурычы—кешеләргә взятка бирү һәм башка юллар белән чималны массовый төстә сатып алып Германиягә экономик байкот оештыру. Моның өчен Англиянең тышкы сәүдә оешмасы, шулай ук Англиянең „промышленность берләшмәсе“ майор карамагына бирелгән. Бу оешманың соңгысына химиклар, төрле белгечлектәге инженерлар һәм техниклар керәләр. Аның шулай ук террорчылар группасы да бар. Бу группаның максаты—нейтраль илләрдә Германиягә каршы юнәлдерелгән саботажлык актлары үткәрү“.

МАННЕРГЕЙМ БАНДАЛАРЫНЫҢ ТЕРРОРЫ

БЕРЛИН, 9 февраль. (ТАСС). „Вестдейчер беобахтер“ газетасының Хельсинкидәге хәбәрчесе Маннергейм бандалары террорының коточкыч картиналарын яза. Хәбәрченең язуына караганда, ак фин властьлары хатын-кызларны, балаларны һәм картларны көчләп урамнарга чыгарып ташлыйлар һәм аларны тирән тылга алып китәләр.

Хельсинкидән куылган тыныч халык шәһәргә кире кайткач, ак фин властьлары аларны шунда ук кире җибәрәләр.

Аннары хәбәрче ак финнәр тылындагы халыкның ачыгуын яза, чөнки икмәк запасы инде беткән. Сөт һәм башка продуктлар бөтенләй юк.

(Телеграммаларның дәвамы 2 нче биттә).

Казан Пехота училищесенең отличникларыннан бер төркем. Беренче рәттә (сулдан): В. С. Лабодин, В. П. Макаров, икенче рәттә—П. А. Вородин, А. Н. Усов һәм Е. Е. Занин иптәшләр. М. Солтанов фотосы.

ССР СОЮЗЫ ОРДЕННАРЫН ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕН ТАПШЫРУ

9 нчы февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин бүләкләнгән кешеләргә орденнар һәм медальләр тапшырды.

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходында хәрәкәттә катнашучыларга—героик хәрәкәт үткәргән өчен, Арктиканың кыен шартларында фәнни тикшерүләрнең киң программасын үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм ныклык күрсәткән өчен—„Георгий Седов“ бозваткыч пароходының капитаны иптәш К. С. Бадигинга, помполит иптәш Д. Г. Трофимовка, капитанның өлкән ярдәмчесе иптәш А. Г. Ефремовка, гедрограф иптәш В. Х. Буйницкийга, икенче механик иптәш С. Д. Токаревка, өченче механик иптәш В. С. Алферовка, радист иптәш А. А. Полянскийга, радист иптәш Н. М. Бекасовка, боцман иптәш Д. П. Буторинга, беренче класс машинист иптәш И. М. Недзвецкийга, машинист иптәш Н. С. Шарыповка, врач иптәш А. П. Соболевскийга, матрос иптәш Е. И. Гаманковка, кочегар иптәш И. И. Гетманга һәм повар иптәш П. В. Мегерга Советлар Союзы Герое исме бирү турында грамота, Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале бирелә.

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходында хәрәкәттә катнашучылар—бүләкләнгән кешеләр исеменнән пароходның капитаны иптәш К. С. Бадигин кыскача речь сөйли.

„Безнең скромный эшебезгә югары бәя биргән өчен, бөек бүләк өчен 15 „седовчы“ моряк исеменнән Ленин—Сталин партиясенә, Совет хөкүмәтенә һәм бөек Сталинга чын күңелдән рәхмәт тапшырырга рөхсәт итегез.

Без Ватаныбыз алдында үзебезне чиксез зур бурычлы дип хис итәбез һәм тормышыбыз соңгы тамчы канына кадәр партиябезнеке һәм бөтен совет халкыныкы икәнлеккә ышандырабыз.

Без нинди генә заданиене дә үтәргә һәр бер минутта хәзер торуыбызга партияне, хөкүмәтне һәм иптәш Сталинны ышандырабыз.

Бәхетле Ватаныбыз чәчәк атсын һәм ныгысын, бөек юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин озак еллар яшәсен!“.

Аннары кече командир иптәш П. Ф. Поросенковка Советлар Союзы Герое исме бирү турында грамота, Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале бирелә. Ул фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен бүләкләнгән иде.

Кызыл Армия сугышчыларыннан, командирларыннан һәм политработникларыннан хөкүмәтнең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәүчеләрдән һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән кешеләрдән бер группага орденнар һәм медальләр бирелә.

Шулай ук икенче бер группа хәрби һәм хуҗалык работникларына да орденнар һәм медальләр бирелә.

Орденнар һәм медальләр бирү тәмам булганнан соң иптәш М. И. Калинин кыскача котлау речь сөйләде. Ул барлык бүләкләнгән иптәшләрне чын күңелдән котлады һәм аларга алдагы эшләрендә уңышлар теләде. (ТАСС).

Чит илләрдә

ФИН СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТЫ РЮЭМЯНЫҢ ТАННЕРГА АЧЫК ХАТЫ

СТОКҺОЛЬМ, 9 февраль. (ТАСС). „Ню даг“ газетасында сеймның элекке социал-демократ депутаты һәм хөкүмәтнең элекке членының улы фин социал-демократы Маури Рюэмяның ачык хаты иглан ителде. Рюэмя бу хатны 19 нчы декабрьдә Таннерга җибәргән иде. „Ню даг“, врач сыйфатында армиягә алынган Рюэмяның шушы хаты өчен кулга алынганлыгын хәбәр итә.

Рюэмя болай дип яза:

„Фин халкының язмышы өчен курку мине сиңа икенче тапкыр шушы хат белән мөраҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Мин бу хатны хосуси тәртиптә язам, ләкин сиңа һәм синең иптәшләреңә фин пролетариатының аңлы өлеше сезнең политикагызны яклый дип әйтергә мөмкинлек калдырмас өчен бу хатны иглан итәм. Мин фронттан язмыйм һәм минем тормышым куркынычта дип һәм мине бу адымны шәхси интересларым өчен ясаган дип бер кем дә әйтә алмас. Мин сез һәлакәткә дучар итәргә теләгән меңнәрчә кешеләр турында уйлыйм. Фин буржуазиясенең политикасы фин халкын анардан күп корбаннар таләп итә торган хәлгә китерде. Гаепнең зур өлеше сиңа төшә дип санап мин сиңа мөраҗәгать итәм. Син эшчеләр сыйнфы максатларыннан өзлексез ерагая барып, 20 ел буена, фактлар белән хисаплашмыйча, һәр вакыт штрейкбрехерлык белән шөгыльләндең. Хәзер син шундый политикага җитәкчелек итәсең ки, бу политика Советлар Союзына каршы дошманлык хәрәкәтләрен ачыктан-ачык һәм яшрен рәвештә яклап кына калмый, бәлки социализм иле белән дуслык мөнасәбәтләренә омтылучыларның барсын да ерткыч әзәрлекләүләргә дучар итә. Хәзер син дәрәҗәңнең иң очына күтәрелдең. Син үзеңә сугышны үзеңнең теләгеңнән тыш тактылар дип әйтәсең. Синең эшеңнең башка нәтиҗәгә китерә алмаячаклыгын ачыктан-ачык икрар итү яхшырак булмас идеме? Барлык башка буржуалар кебек үк, син социализм эшенең киләчәге юк һәм Советлар Союзы җимерелер дип санадың. Хәзер син үз тормышыңның максаты чигенә җиткәнлектән мин сиңа мөраҗәгать итәргә телим. 20 ел буена син эшчеләр сыйнфын аеруга юнәлдерелгән политика алып бардың. Хәзер син культураны нак Франко саклаган кебек, демократияне һәм гуманизмны сиңа Финляндиягә офицерлар һәм очучылар җибәрергә вагдә иткән Муссолини яклаган кебек яклыйсың. Билгеле, Маннергейм сине „эшчеләр хәрәкәтенең бөек максатларына“ алып килер.

Сиңа шуны аңлатырга тиешмен: Финляндия пролетариатын сугышка аның теләгенә каршы килеп җибәрәләр һәм ул Советлар Союзы белән дусларча мөнасәбәттә булырга тели. Эшчеләр оешмаларының шактый өлешенең җыелышлар үткәрергә һәм эшчеләр сыйнфы интересларына каршы килә торган карарларга каршы чыгарга мөмкинлеге күптән бетерелде инде. Мин уйлыйм, син бу хатны алган моментта синең исмең йөзләрчә эшчеләрнең һәм крестьяннарнең үлүендә гаепләнүче үтерүче исме сыйфатында тамгаланыр. Бу санны меңгә кадәр җиткергәнче уйлап кара. Син—хәзерге сугышны кабызучыларның берсе. Тарих мәйданыннан синең тизрәк китүең һәм бу урынны сәләтлерәк кешеләргә бушатуың яхшырак“.

АК ФИНЛЯНДИЯДӘГЕ ХӘЛ

СТОКҺОЛЬМ, 9 февраль. (ТАСС). Ак Финляндиядә халык һәм солдатлар арасында ризасызлык көннән-көн үсә. Соңгы вакытта ак финнәр армиясендә массовый төстә дизертирлык башланды. Шул уңай белән ак фин властьлары „Әгәр призыв яшендәге кешеләр үз частьләре урнашкан районнан башка урында күренсәләр, аларның хәрби формадамы, яки түгелме икәнлекләренә карамастан, барсын да тотарга һәм тентергә“ приказ бирделәр.

Шуның белән бергә, ак Финляндиядән фин буржуазиясенең качуы турындагы мәглүматлар чит илләргә көннән-көн ешрак чыга. Фин буржуазиясе Швеция чигенә барып җитү өчен төрле хәйләләргә бара. „Йорттагы хәлләр буенча“ китү сылтавы астында барон Маннергеймның „патриотлары“, үзләренең барлык капиталларын һәм кыйммәтле нәрсәләрен алып, Швециягә качалар. Фин ак гвардеецларының „Або ундерретельсер“ газетасының язуына караганда, хәзер жандармериягә „бер урыннан икенче урынга күчүче гражданнарның багажларына контроль куярга“ һәм „чит илгә акча һәм кыйммәтле кәгазьләр алып чыгуга тоткарлык ясарга“ приказ бирелде.

Ак финнәрнең финанслары шартлый. Үзләренең саеккан кассаларын тутыру өчен, Маннергейм властьлары халыкка көч җитмәслек налоглар, җыемнар салалар. Фин ак гвардеецларының „Суомен сосиалдемократти“ газетасында күптән түгел „Үзеңнең квартираң өчен түләү—семьяңне саклау“ дигән исемдә мәкалә урнаштырылды. Ак фин властьларының барлык күчеп киткән халыклар квартира түләвен мәҗбүри рәвештә кертергә тиешләр дигән боерыгы әнә шундый „лозунг“ белән аңлатыла. Үзләренең йортларыннан көчләп куылган кешеләрнең яшәү средстволары булмый һәм алар шулай итеп яңа мәсхәрәләнүләргә дучар ителәләр.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партиянең җитәкче органнарына сайлауларга хәзерлек башланды

КИРОВ РАЙОНЫНДА

Киров районында башлангыч партоешмаларның отчет-сайлау җыелышларына хәзерлек эше җанлы рәвештә бара. Шушы уңай белән, 7 нче февральдә ВКП(б) райкомы партоешма секретарьларының киңәшмәсен үткәрде. Бу киңәшмәдә „Партия органнарын сайлауны үткәрү турында“ ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде. Отчет-сайлау җыелышларын үткәрүгә хәзерлек һәм аларны үткәрү вактында башлангыч партоешмаларга булышлык күрсәтү өчен партиянең район активыннан 45 коммунист билгеләнде. Районның барлык башлангыч оешмаларында отчет-сайлау җыелышларына хәзерлеккә багышланган партҗыелышлар үткәреләчәк. Бу җыелышларда отчет-сайлау вактында коммунистларның бурычлары турында мәсьәлә куелачак.

МЕХКОМБИНАТ ПАРТОЕШМАСЫНДА

Мехкомбинат партоешмасы партиянең җитәкче органнарын сайлауларга хәзерләнә.

10 нчы февральдә цех партбюро һәм партгруппа җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрелде. Киңәшмәдә отчет-сайлау җыелышларына хәзерлек чаралары тикшерелде. Комбинат партоешмасының, цех партоешмаларының һәм партгруппаларның отчет-сайлау җыелышларын үткәрү көннәре билгеләнде. Цех партоешмаларына һәм партгруппаларга отчет төзү һәм гомумән җыелышка хәзерләнү эшенә ярдәмгә актив коммунистлар беркетелде. Йорт хуҗайкасы һәм пенсионер булган коммунистлар арасында сайлау инструкциясен аңлату һәм аларның отчет-сайлау җыелышларына тулы килүләрен тәэмин итү эшенә аеруча игтибар итәргә кирәклеге күрсәтелде. Отчет-сайлау җыелышы алып барылган көннәрдә балалы хатыннар өчен ясле һәм балалар бакчасы булдыру да исәпкә алынды.

Партбюро секретаре иптәш Кузьмин сайлаулар уңае белән алда торган бурычларны һәм үткән сайлаулардагы кимчелекләрне күрсәтеп үтте. Цех партоешмаларында һәм партгруппаларда отчетлар төзү эшләре белән бергә, партия хуҗалыгын тулы тәртипкә китерергә кирәклеге күрсәтелде.

И. А.

АВЫЛ РАЙОННАРЫНДА

Тәкәнеш районында партиянең башлангыч оешмалары отчет-сайлау җыелышларын үткәрүгә хәзерләнә башладылар. 9 нчы февральдә ВКП(б) райкомы башлангыч партоешмаларның секретарьлары һәм партия оештыручылары белән киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә катнашучылар ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе белән таныштылар. Хәзер барлык партоешмаларда җыелышларга хәзерлек эшләре алып барыла.

***

ВКП(б) ның Югары Ослан райкомы партиянең җитәкче органнарына сайлаулар үткәрү планын һәм срокларын раслады.

8 нче февральдә партиянең башлангыч оешмалары секретарьлары белән киңәшмә уздырылды.

***

ВКП(б) ның Буденный райкомы 9 нчы февральдә партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының һәм партия оештыручыларының киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә ВКП(б) Үзәк Комитеты инструкциясе өйрәнелде.

Райком бюросы партия органнарына сайлаулар үткәрү планын раслады.

Югары Ослан урта мәктәбе янындагы комсомол оешмасы секретаре иптәш Галиев (унда) комсомолецларга ВЛКСМ ның Татарстан оешмасы активы җыелышы материалларын укый. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Дөрес булмаган позиция

(„Правда“ ның Татарстан АССР дагы хәбәрчесеннән)

Татарстанда авыл хуҗалыгы уңышлары турында сөйләргә яраталар. Шул уңай белән утырышларда һәм киңәшмәләрдә речьләр сөйләнә, җирле газеталарда зур мәкаләләр басыла.

Январьда партия Өлкә Комитетының пленумы булды. Республиканың Совнарком председателе иптәш Тынчеров язгы чәчүгә хәзерлек турында доклад ясап, докладының шактый өлешен республикадагы колхозларның һәм совхозларның үткән елны югары уңыш өчен көрәштә зур уңышларга ирешкәнлекләрен нигезләүгә багышлады.

Пленумда катнашучылар барсы да шул карашта булдылар һәм ул карарда да чагылды. Бу карарда пленум „үткән 1939 нчы елның Татарстан АССР да авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа уңышлар белән билгеләнгәнлеген күрсәтеп үтә“.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының әле яңа гына булып үткән республика киңәшмәсендә партия Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев доклад ясады. Ул да колхозларның һәм совхозларның үткән елны зур уңышларга ирешкән булуларыннан башлады. Ә киңәшмә мөраҗәгатендә „зур уңышлар“ „гаять зур уңышлар“ итеп күрсәтелгәннәр инде.

Билгеле, республика оешмаларының җитәкчеләре кимчелекләр турында да дәшми калмыйлар. Ләкин алар турында теләмичә генә, форма өчен булган кебек кенә әйтелә. Партия Өлкә Комитеты пленумының карарында бу турыда түбәндәгеләрне күрергә мөмкин: „шушы уңышлар белән бер рәттән, авыл хуҗалыгының аерым эшләрен үтәүдә җидди кимчелекләргә дә...“ юл куелган.

Шулай итеп, уңышлар турында бөтен тавыш белән һәм торган саен көчәя бара торган тон белән зур, эре, гаять зур уңышлар дип әйтелә. Кимчелекләр турында исә—шыпырт кына, сүз арасында гына сөйләнә. Речьләрнең, карарларның, мөраҗәгатләрнең бөтен мәгънәсе түбәндәгечә: Татарстанның авыл хуҗалыгы күтәрелештә һәм бары тик аерым кимчелекләр генә зур югарылыкка күтәрелергә комачаулыйлар.

Болай бәя бирү дөресме? Юк, ялгыш.

Икенче бишьеллык еллары Татарстан авыл хуҗалыгының көчле үсүе чоры булдылар. Бөртекле ашлыкларның уртача уңышы гектарыннан 1933 нче елны 8,9 центнер булган булса, 1937 нче елны 14,4 центнерга кадәр күтәрелде. Иген уңышы буенча сугышка кадәрге дәрәҗә ике тапкыр чамасы узып кителде. Татарстанның авыл хуҗалыгында колхоз строеның көче әнә шулай күренде.

Ирешелгәннәрне ныгытып, алга барырга гына кирәк иде. Кызганычка каршы, бу хәл булмады. 1938 нче елны бөртекле культуралар буенча уртача уңыш 9,7 центнер, 1939 нчы елны 6,9 центнер булды. Шулай итеп, соңгы ике ел эчендә Татарстан авыл хуҗалыгы бөртекле ашлык буенча артка атлады.

Шуның белән бергә республика оешмалары җитәкчеләренең вагдәләргә юмарт булулары, ләкин шул ук вакытта алынган йөкләмәләрне үтәү өчен көрәшмәүләре бик характерлы. Мәсәлән, үткән елның февралендә партия Өлкә Комитеты пленумы кабул иткән карарда болай дип язылган иде: „Татарстан АССР колхозларының һәм совхозларының, һава шартлары нинди булуга да карамастан, быел ук инде гектарыннан кимендә 13—14 центнер бөртекле ашлык уңышы алырга барлык мөмкинлекләре бар“. Шулардан чыгып, Башкыртстан АССР белән төзелгән социалистик ярыш договоры буенча Татарстанда гектарыннан 13 центнер бөртекле ашлык алу турында йөкләмә алынды.

Ә хәзер һәр җирдә „һава шартларының бик начар булуы“ турында сөйлиләр.

Яз көне—һава шартлары нинди генә булса да югары уңыш үстерү турында ант итеп ышандырулар. Кыш көне—яңгырлар булмауны сылтау итү. Ләкин икесенең берсе: я кешеләр йөкләмәләрне ышанмыйча алалар, яки йөкләмәләр үтәлерлек була, ә җитәкчеләр эшне йөкләмәләрне үтәрлек итеп оештыра алмыйлар.

Шулай да, ни өчен соң соңгы ике ел эчендә иген уңышы ике тапкыр кимеде? Бу вакыт эчендә Татарстан авыл хуҗалыгының техника белән коралллануы үсте. Үткән елны гына да тракторлар һәм камбайннар 17 процентка артты. Югары уңыш алу тәҗрибәсе дә күбәйде.

Эш менә нәрсәдә: авыл хуҗалыгы эшенең сыйфаты начарланды. 1939 нчы елны трактор эшләре планы 77,3 процентка гына үтәлде. 15 кечле трактор белән уртача эшләү соңгы елда 93 гектарга кимеде.

Туңга сөрелгән җирләрне культивацияләү өчтән ике өлешкә, пропашнойларны культивацияләү—11,6 процентка үтәлде. Пар күтәрү май ае урнына июльдә тәгәлләнде. Туңга сөрелгән җирләрне яңадан сөрү планы 62 процентка гына үтәлде.

Тирән сөрү урнына күп урыннарда сай сөрәләр. Мәсәлән, Яңа Чишмә һәм Тымытык районнарында сөрелгән җирләрнең 4,8 проценты гына 18—20 сантиметр тирәнлектә сөрелгән, нигездә колхоз кырларында сөрү 14—16 сантиметр тирәнлегендә, еш кына аннан да саерак үткәрелә.

Иген уңышы кимүнең чын сәбәпләре әнә шулар.

Колхоз производствосының икенче бер хәл иткеч тармагы булган терлекчелектә дә эш яхшыдан түгел. Соңгы ике ел эчендә Татарстанда мөгезле эре терлекләр саны кимеде. 1 нче январьга барлык төр терлекләр буенча яңа фермалар төзү планнары да, аларга терлекләр туплау планнары да үтәлмәде. Дуңгыз үрчетү буенча 777 ферма урнына 299 ферма төзелде, ә аларга дуңгызлар туплау планы 29,2 процентка гына үтәлде. Сарык үрчетү буенча 1.338 ферма урнына 984 ферма төзелде. Ә аларга терлекләр туплау планы 27,7 процентка гына үтәлде.

Татарстанда үткән елны һәр гектардан 13 һәм хәтта 15 центнер бөртекле ашлык җыеп алган 200 ләп бригада һәм звено бар. Бу, алдынгыларның тәҗрибәсе агротехниканы барлык колхозларда да чын-чынлап кулланганда бөтен республикада уңыш югарырак булачакны күрсәтә.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Татарстан партия оешмаларының иң беренче бурычы артта калуны бетерүгә колхозчылар массасын туплаудан һәм алдынгы колхозларның һәм бригадаларның тәҗрибәсен нак шушы мәгънәдә популярлаштырудан гыйбарәт иде. Ә Татарстанда башка юл белән киттеләр—аерым уңышларны гомуми уңышлар итеп күрсәтәләр, ә шактый артта калуны—аерым кимчелекләр итеп күрсәтәләр.

Бу дөрес булмаган позициянең нинди зарар китерүен әйтеп торуның кирәге бармы!

Г. Окулов.

„ПРАВДА“. 8 февраль.

ФИН АК ГВАРДЕЕЦЛАРЫНА КАРШЫ СУГЫШЛАРНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ

Данлыклы күпләрнең берсе

Иван Ершов—тәбәнәк буйлы, таза кеше. Анарда күзгә бәрелеп торырлык артык бер нәрсә дә юк—тик менә соры күзләре генә саргылт кашлары астыннан җемелдәп торалар, җылы, матур итеп елмаюы аның йөзен яктырта. Ул

Иван Ершовның хәтерендә мәңге калыр. Полк тревога буенча күтәрелгәндә төн уртасы иде әле.

Политрук Иван Ершов ротадагы сугышчыларны үз тирәсенә җыеп, речь сөйләде. Ул ак фин-

Иртә белән тагын алга киттеләр. Менә елга, су аркылы кичү. Кичү урны янында—дошман...

Автоматларның ату тавышлары өзлексез яңгырый. Пулеметлар туктаусыз атып торалар.

Сугышчылар арасында тоткарлык туа. Шул чагында һәр вакыттагы тынычлык белән Иван Ершов күтәрелә:

— Алга, иптәшләр. Финнәрне тар-мар итәргә. Әйдәгез!

Ершов артыннан рота күтәрелә һәм алга ыргыла. Финнәр коралларын ташлап, урманга кереп качалар. Безнекеләр елганы кичәләр.

Сугыштан соң, арганлыгын онытып, политрук барлык сугышчыларны тикшереп чыкты, берсен рухландырды, икенчесен ачуланды, өченчесен мактады.

— Кыю кешедән пуля курка, ә куркакны пуля һәр вакыт таба. Онытмагыз,—диде ул.

Иван Ершов, командир белән берлектә, кемнең ничек киенгәнлеген тикшерде, сугышчыларның вактында ашатылуларын күзәтеп торды. Тик шуннан соң гына ул агач төбе өстенә утырып, кыска тунын чишеп җибәрде.

Төнлә рота Ш. хуторын алды. Аның аз санлы кешеләре урманга качканнар иде, дозор аларны алып кайтты. Алар бер төркемгә җыелып, куркышып һәм кыюсызланып кызыл армеецларга карадылар.

Иван Ершов бер крестьян белән үзенең консервларын уртаклашты. Бер кечкенә кызга шикәр бирде. Кыз елмайды.

Өйгә керделәр. Беренче куркуның эзе дә калмаган йорт хуҗасы патефон уйната башлады. Иван Ершов музыка тыңлады. Арганлыктан аның башы салынып төште, ләкин йокларга вакыт юк иде: алга һәм алга барырга кирәк иде.

Ершов сугыш бәрелешләрен искә ала,—бу аз гына көннәр эчендә алар бик күп булдылар. Ротаның С. шәһәрчеге якынындагы биеклекне ничек штурмлавын, кешеләрнең „Сталин өчен, Ватан өчен!“ дигән авазлар белән сугышка баруларын, ак финнәрнең кар белән капланган тау битендә үзләренең үлгән кешеләрен калдырып качуларын искә ала.

9 нчы декабрьдә рота сугышып икенче кичүне алды. Дошман флангтан ут ачып, кысрыклый башлый. Хәл сәгать саен кискенләшә. Бераз гына вакытка дошман элемтәне өзәргә өлгерә. Аның көчләре арта.

Рота бик нык сугышты. Чигенергә урын юк иде. Дошманнар һәр яктан киләләр иде. Йөз кеше үләргә, ләкин бирелмәскә карар бирделәр. Рота командиры лейтенант Ардельян яраланды. Ул авыртуны җиңеп, оборонага җитәкчелек итүне дәвам иттерде. Икенче пуля аның йөрәгенә эләкте.

Иван Ершов дусы—командиры өстендә баш иде. Күзләреннән яшьләр акты, ләкин салкын җил аларны киптерде.

Ершов:

— Кызганыч, бик кызганыч... иптәшләр, ләкин финнәргә бу арзанга төшмәс. Дөресме? диде.

Финнәр дүрт тапкыр атакага чыктылар, рота аларны дүрт тапкыр кире кайтарды.

Иван Ершовның аягы яраланды. Ул үзенең яралануын иптәшләреннән яшерергә тырышты, ләкин кан киез итектән үтеп чыкты һәм кар өстендә кан эзе калды. Ершовны госпитальгә озаталар...

***

Ике көннән ул шыпырт кына госпитальдән качмакчы була. Ершовны ярты юлда туктаталар. Врач аны озак үгетли, ә аннары, ачуланып кычкыра һәм аяклары белән тыпырчына:

— Сез акылдан яздыгызмы, сезгә әле кимендә тагын өч атна ятырга кирәк. Мин сезгә такдим итәм...

— Доктор, аңлыйсызмы, булмый... рота. Иптәшләр.

— К чорту. Ул турыда уйлауны да тыям. Хәзер мин сезнең өчен җаваплы.

Иван Ершов, медицинаны дөньядагы иң начар сүзләр белән сүгеп, үзенең язмышына буйсынды.

Күптән түгел ул үзенең Ленин ордены белән бүләкләнүен белде. Ул, тәэсирләнеп Ершово авылына, ата-аналарына һәм ротадагы иптәшләренә хат язды. Аннары танышларыннан һәм таныш булмаганнардан котлау хатлары килә башлады.

Ленинградтан нининдидер бер кыз яза: „Героем. Мин сезгә сокланам һәм сезнең өчен шатланам. Мин сезнең белән таныш түгел, ләкин сезне күз алдыма китерәм: сез, могаен, озын буйлы, матур кешедер, сезнең күзләрегез карадыр...“.

Ахрында аны госпитальдән чыгаралар. Ул врачлар белән ягымлы итеп һәм чын күңелдән, ләкин ашыгычлык белән саубуллаша. Мөмкинлек булу белән үк ул ротага китә. Бу вакытта аның полкы—81 нче полк Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән иде инде.

Н. Кружков.

ХАТЫН-КЫЗЛАРДАН КҮП САНДА МЕХАНИЗАТОР КАДРЛАР ХӘЗЕРЛИК

Социалистик төзелештә хатын-кызлар гаять зур көч. Партиябез, хөкүмәтебез тәрбиясендә үскән бик күп хатын-кызлар үзләрен илебезнең геройлары, атаклы кешеләре, социалистик җәмгыятнең актив төзүчеләре итеп таныттылар. Хатын-кызлар промышленностьта булсын, авыл хуҗалыгында һәм транспортта булсын катлаулы машиналарны идарә итәләр һәм бик яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр. Тымытык МТС ында тракторчы, комбайнчы булып эшләүче хатын-кызларның эш үрнәкләре мисалендә моны ачык күрергә була.

Фәридә иптәш Зарипова җитәкчелек итә торган тракторчы хатын-кызлар бригадасы берничә ел инде МТС та алдынгы урыннарның берсен алып килә. Үткән ел МТС та һәрбер СТЗ тракторы белән, йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә, 860 гектар эшләнгән булса, иптәш Зарипова бригадасы шушы ук маркалы һәр трактор белән 953 гектар эшләгән һәм ягулыкка 1.680 килограмм экономия ясаган. Бу бригада иптәш Миннуллин бригадасы белән ярышып эшләгән һәм ярышта алдынгылыкны алган. Иптәш Зарипова бригадасы иптәш Миңнуллин бригадасына караганда, трактор башына 58 әр гектар артык эшләгән һәм ягулыкка экономияне 633 килограмм артык ясаган.

Хатын-кызлар бригадасында аерым иптәшләр тагын да югарырак күрсәткечләр биргәннәр. Җиһан иптәш Зарипова үз сменасында 501 гектар, Мәүҗүдә иптәш Шакирова 494 гектар, иптәш Исламова 439 гектар эшләп, ягулыкка күп кенә экономия ясаганнар. Бу иптәшләр 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашканнар һәм 1940 нчы елда да аңа катнашу өчен гариза биргәннәр. Тракторда эшләү буенча яхшы эш үрнәкләре күрсәтүче Зарифа иптәш Мәрдәншина хәзер механиклар хәзерләү курсында укый.

Тракторчы хатын-кызлар бригадасы язгы чәчү эшләренә хәзерләнү буенча да үзенең эшен үрнәк рәвештә оештырган. Тракторларга ремонт ясауны МТС та беренче булып тәгәлләгән. МТС та тракторларга ремонт ясау 1939 нчы елның 24 нче декабренә тәгәлләнгән булса, хатын-кызлар бригадасы үз тракторларына ремонт ясауны 1 нче ноябрьгә үк тәгәлләгән. Тракторчы хатын-кызлар бригадасының машиналарга ремонт ясаудагы стахановча эш үрнәкләрен башка бригадаларга да күчерү нәтиҗәсендә, Тымытык МТС ы тракторларга ремонт ясау буенча республикабызда алдынгы урыннарның берсен алды.

Бу мисальләр авыл хуҗалыгы производствосының хәл иткеч тармагында хатын-кызларның гаять зур урын тотуы, мондый кадрларны хәзерләү эшен күп тапкыр көчәйтергә кирәк булуы турында сөйлиләр. Тымытык районында бу факттан яхшы нәтиҗә ясаганнар. Вахитов исемендәге совхозда 22 хатын-кыз производстводан аерылмыйча тракторчылар хәзерләү курсын тәмам итеп чыккан. Укып чыгучылардан 7 кеше курсны отлично билгесенә һәм 11 кеше яхшы билгесенә тәмамлаган.

Хәзер Чаллы МТС ы тарафыннан оештырылган курсларда 45 хатын-кыз, Тымытык МТС ында 56 хатын-кыз укый. Димәк, быел ике МТС тагы тракторчыларның 60—70 процентын хатын-кызлар тәшкил итәчәк.

Курсларда укулар яхшы гына оештырылган. Тельман исемендәге колхозда оештырылган курс белән Сукаеш авылындагы курслар арасында социалистик ярыш договоры төзелгән. Ярыш шартларында: укучыларның дәрескә яхшы хәзерләнеп килүләре, укуда артта калып баручыларга ярдәм оештыру, программа материалларын яхшы үзләштерү һәм курсны тәмамлаганда барлык укучыларның тракторчы исме алып чыгуларына ирешү һ. б. турында әйтелә. „Марс“ колхозындагы курста укучылар „Мелиорация“ колхозындагы курсларда укучылар белән ярышалар.

Курслар бина, укытучылар һәм язу-сызу кирәкләре белән тәэмин ителгән. Дәресләр Наркомзем тарафыннан кабул ителгән программа буенча, һәр көн 3 сәгат була. Ләкин курслар өчен татар телендә дәреслекләр һәм методик кулланмалар булмавы эштә зур комачаулык тудыра. Гомумән, хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү эшенә Татнаркомзем тарафыннан җитәкчелекнең һич тә канәгатьләнерлек булмавын күрсәтергә кирәк. Наркомзем бу өлкәдә Тымытык районындагы кебек уңышлы эш тәҗрибәләрен башка районнарга һәм МТС ларга да күчерү белән нык шөгыльләнергә, бу эшкә оператив җитәкчелек итәргә тиеш. Барлык МТС ларда һәм совхозларда да хатын-кызлардан күп санда механизатор кадрлар хәзерләү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

А. Вәлиев.

КОЛХОЗЛАРДА АГРОТЕХНИКА УКУЛАРЫ

Юдино районының 19 колхозында агротехниканы өйрәнү түгәрәкләре тәртипле рәвештә эшләп киләләр. „Маяк №1“ колхозында 2 түгәрәк оештырылды. Аларга 60 колхозчы йөри. Түгәрәкләргә агротехник Әхмәдуллин һәм колхозның тәҗрибәле бригадиры Фәйзуллин иптәшләр җитәкчелек итәләр. Фрунзе исемендәге колхозда да агротехника түгәрәгенең занятиеләре тәртипле рәвештә, 5 көнгә бер тапкыр үткәрелеп киленә. Бу түгәрәктә 45 кеше укый.

„Горняк“, Киров исемендәге һәм башка колхозларда да агротехника түгәрәкләре системалы рәвештә эшләп киләләр.

(ТатТАСС).

Балык Бистәсе районының „Авангард“ колхозы члennары авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ (сулдан): колхозчылардан Ф. Иванов, Н. Павлов. Д. Степанов, М. Сычев һәм А. Осипова иптәшләр мөраҗәгатне укыйлар. Л. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

АЛДЫНГЫЛАР КИҢӘШМӘСЕНЕҢ МӨРАҖӘГАТЕН ТИКШЕРӘЛӘР

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ ҖӘЕЛӘ

ӘЛМӘТ, 9 февраль. (Телефон буенча). Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе мөраҗәгатен зур күтәренкелек белән каршыладылар. Бу мөрәҗәгат колхозларның кырчылык, трактор бригадаларының һәм ферма эшчеләренең гомуми җыелышларында өйрәнелә. Колхозларда бригадалар йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылып үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр.

„Ярыш“ колхозының Зәйнәп иптәш Кәримова (авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе делегаты) җитәкчелек итә торган 4 нче бригада һәм иптәш Әсәдуллин бригадасы югары уңыш яулап алу өчен социалистик ярыш договорлары төзеделәр. Иптәш Кәримова бригадасы язгы чәчүгә үрнәкле рәвештә хәзерләнә. Кырга 500 йөктән артык тирес чыгарылды, көл һәм кош тизәкләре җыю планы тулысынча үтәлде. Бригада членнары агротехниканы кызыксынып өйрәнәләр. Ике бригада да язгы чәчүне иң кыска срокта, 7 эш көнендә тәгәлләү өчен йөкләмә алды.

„Кызыл Карван“ колхозы колхозчылары „Радио“ колхозын социалистик ярышка чакырдылар. „Кызыл Карван“ колхозы бригадиры иптәш Нургалиев язгы чәчүгә яхшы хәзерлек алып бара. Бригада чәчү машиналарына һәм башка инвентарьларга ремонт эшен тәгәлләде. Бригаданың ат караучылары атларның язгы чәчүгә җитәрлек көрлектә булуларын тәэмин итү өчен көрәшәләр. „Дирижабль“ колхозының иптәш Хисамиев бригадасы бөртекле культураларның һәр гектарыннан 105 пот уңыш алу өчен йөкләмә алып, башка бригадаларны социалистик ярышка чакырды.

З. Салахеттинов.

ЗУР КҮТӘРЕНКЕЛЕК ТУДЫРДЫ

АКТАНЫШ, 10 февраль. (Телефон буенча). Шушы көннәрдә авыл советы һәм колхоз председательләренең, бригадирларның район киңәшмәсе үткәрелде. Бу киңәшмәдә авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгате өйрәнелде һәм мөраҗәгаттә күрсәтелгәннәрне практик тормышка ашыру буенча конкрет чаралар билгеләнде. Киңәшмәдә катнашучылар районда язгы чәчүгә хәзерлекне Кызыл Армиянең һәм Хәрби-Диңгез Флотының XXII еллыгы көненә тәгәлләү бурычын куйдылар.

Киңәшмәдән соң күп кенә колхозларның эшендә кискен борылыш булды. Куйбышев исемендәге колхоз (председателе иптәш Гыйлаҗов) язгы чәчүгә хәзерлекне тәгәлләде инде. Бу колхозда басуга тирес чыгару планы 102 процент, кар тоту планы 135 процент итеп үтәлде. Язгы чәчү өчен кирәкле чәчү орлыклары тиешле кондициягә җиткерелде. Орлыклар яхшы урында саклана. Атларның көрлеге яхшы.

Шулай ук „Тимер кул“ колхозында да (председателе иптәш Әхмәдуллин) язгы чәчүгә хәзерлек эшләре яхшы бара. Тирес чыгару планы 80 процент, кар тоту планы 150 процент итеп үтәлде. Чәчү орлыклары җитәрлек хәзерләнде.

Колхозчылар арасында авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен өйрәнгәннән соң Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә хәзерлек эшләре дә сизелерлек яхшырды. 1940 нчы елда күргәзмәгә катнашырга теләп 200 гариза бирелде. Хәзерге вакытта бу гаризаларны рәсмиләштерү эшләре бара.

Ә. Сафин.

Район җир бүлегенең өлкән агрономы, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе делегаты.

1940 НЧЫ ЕЛ НАВИГАЦИЯСЕН ҮРНӘК РӘВЕШТӘ КАРШЫЛАУ ӨЧЕН

ЭШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРӘЛӘР

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү турында москвалылар чакыруына Чистай шәһәрендәге суднолар ремонтлау заводы эшчеләре, инженер-техник работниклары практик эш белән җавап бирәләр. Завод коллективы 1940 нчы елның 1 нче квартал планын вактыннан элек, югары сыйфатлы итеп үтәү өчен намус белән көрәшә.

Тимерчелек цехы стахановчылары бер горнда эшләү урнына ике-өч горнда эшләү методын уңышлы үзләштерәләр. Тимерче иптәш Щепетев бу башлангычның инициаторы булды һәм хәзер ул берьюлы өч-дүрт горнда эшләүгә күчте. Нормасын 300—350 процент итеп үтәгән хәлдә, сыйфат күрсәткечләрен дә югары тота. Бу башлангычка Холоденин, Буторин иптәшләр дә кушылдылар һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә үрнәк күрсәтәләр.

Яш мастер, коммунист иптәш Гагарин тарафыннан җитәкчелек ителә торган электросварка цехы аеруча яхшы эшли. Ул январь ае планын вактыннан элек арттырып үтәде. Бу уңышын цех коллективы февральдә дә ныгыта. Мактаулы стахановчылар Солохов, Поспелов, Милютин иптәшләр көнлек норма үтәлешен 400—500 процентттан киметмиләр.

Механика цехы эшчеләре дә алдынгылардан калышмыйлар. Берьюлы берничә станокта эшләүче строгаль Ватанин, токарь Носков, Пепеляев, Гибалин һәм башка иптәшләр нормаларын 600—700 процент итеп үтиләр.

Судноларга ремонт ясау эшен башкаручы бригадалар зур күтәренкелек белән эшлиләр. Социалистик ярышта алган йөкләмәләрне үтәү өчен ремонтчы бригадалар үзара социалистик ярышны киң җәелдерделәр. Ярышта алган йөкләмәләр эш белән ныгытыла. Мәсәлән, „Камская 15“, „Балхаш“, „Жимчужина“, „Таджикия“, „Татария“ һәм башка пароходларга ремонт ясау нигездә тәгәлләнде дияргә була. Гадәттә яз көне башкарыла торган буяу эшләре генә калды.

Кыскасы, Чистай шәһәрендәге суднолар ремонтлау заводы үзенең эшен яхшыртуда борылыш ясады. Пермь шәһәрендәге Дзержинский исемендәге завод коллективы белән ярышта алда бара. Декабрь һәм январь айларының планы арттырып үтәлде. Тик менә заводның тәэминат, план һәм техник бүлекләре генә борыла алмаучылык күрсәтәләр. Бу кимчелекләр булмаганда завод тагын да яхшырак эшли алыр иде.

***

Заводта быел техника укуларын оештыруга зур игтибар бирелә. Кама пароходчылыгы техника укуларын оештыру өчен заводка 250 мең сумга якын акча җибәрде.

Завод идарәсе янындагы техкомбинат практик эшкә башлады. Хәзер монда судно капитаннары һәм механиклар өчен курс оештырылды. 500 дән артык кеше техминимум курслары аша үткәреләчәк.

Моңардан тыш техкомбинат янында социалистик хезмәт мастерлары өчен ике еллык мәктәп оештырыла. Мәктәптә 120 стахановчы укыячак.

П. Кащеев.

ЧИСТАЙ ПРИСТАНЕНДӘ

Чистай пристане, Сарапуль пристане белән ярышып, 1940 нчы елның навигациясенә эшлекле рәвештә хәзерләнә. Вокзалны ремонтлау кызу темп белән бара. Ана һәм бала бүлмәсе, билет кассалары җиһазландырыла, дебаркадерга барьерлар ясала. Пассажирларга культура хезмәте күрсәтү өчен уку залы, буфет, ашыгыч ярдәм пункты, багаж саклау камерасы һәм номерлар җиһазландырылачак.

Пристаннең үлчәү хуҗалыгы тәртипкә китерелде. 900 тонна йөк сыярлык ике лабаз хәзерләнде. Йөк озатучылар белән договорлар төзү башланды.

КАМА ТАМАГЫ ПРИСТАНЕ АКЫРЫН КУЗГАЛА

Кама Тамагы пристане ике елганың тоташкан урнындагы гаять әһәмиятле узел. Аның аркылы меңнәрчә тонна йөкләр, күп санда пассажирлар үтә. Шуңар күрә дә бу пристань 1940 нчы ел навигациясенә аеруча нык хәзерләнергә тиеш иде. Ләкин аның хәзерлеге һич тә канәгатьләнерлек түгел әле.

Судноларга ремонт ясау темпы бик акырын бара. Бу эштә ныклы график юк. 131 нче номерлы дебаркадерга ремонт ясау озакка сузылды. „Инженер Кибальчич“ пароходы белән дә эш әнә шулай тора. 71 нче номерлы баркаска ремонт ясау планы 31 процент, „Балтвод“ баркасына 30 процент кына үтәлде.

Пристань кадрлар белән кирәгенчә тәэмин ителмәгән. Бигрәк тә операторлар, диспетчерлар җитешми.

Шушы көннәрдә Кама Тамагы пристане партбюросы утырышында пристань начальнигы иптәш Бушуевның доклады тыңланды. Чыгып сөйләүче иптәшләр навигациягә хәзерлекнең начар торуын тәнкыйть иттеләр. Профсоюз оешмасы да бу тармакта үзенең бурычын тулы үтәми. Су юлы работниклары арасында социалистик ярышка, стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек бик йомшак. Москва инструментальчыларының чакырулары шушы көнгә кадәр тикшерелмәгән.

Хуҗалык һәм сәүдә оешмалары белән договорлар төзү буенча да күп җитешсезлекләр бар. Җирле әһәмияткә ия булган 4.000 тонна йөктән бары 700 тоннасына гына договор төзелгән. Пристань җитәкчеләре „навигациягә әле вакыт аз түгел“, дигән настроениегә бирелгәннәр.

Кама Тамагы пристаненең навигациягә тулы хәзерлек белән килүен тәэмин итәргә кирәк.

К. Гайнанов.

КАРАЛМЫЙ ЯТКАН ТАКДИМНӘР

„Кызыл Тукучы“ фабрикасында (Кукмара) уйлап табу һәм рационаллаштыру эшләрен яхшырту буенча тиешле чаралар күрелми әле. 1939 нчы елда стахановчылардан һәм инженер-техник работниклардан 61 такдим алынды. Болардан бары тик 17 такдим генә тормышка ашырылган. 220 мең сум экономия бирерлек калган 41 такдим шушы көнгә кадәр хәрәкәтсез яталар.

Фабриканың уйлап табучысы иптәш Шелинин моннан 3—4 ай элек молотки машиналарының эшен яхшырту, агарту цехындагы станокларның конструкцияләрен үзгәртеп кору буенча бик кыйммәтле такдимнәр биргән иде. Бу такдимнәр фабриканың механика цехы һәм конструкторлар бюросы җитәкчеләре Радигин һәм Авакумов иптәшләр гаебе белән хәзергәчә тормышка ашырылганы юк.

Уйлап табу һәм рационализаторларның иҗадларына шундый игтибарсыз карау аркасында уйлап табучылар саны да бик акырын үсә. Фабриканың партия, профсоюз оешмалары бу эш белән җитәрлек кызыксынмыйлар. 1939 нчы елда бу эшнең торышы турында фабком утырышында бер тапкыр да куеп тикшермәделәр.

Фабрика җитәкчеләре бу фактлардан тиешле нәтиҗә ясарга тиешләр.

Морат Әхәт.

МЕХАНИЗАТОР КАДРЛАР ХӘЗЕРЛӘҮГӘ БОЛЬШЕВИСТИК ҖИТӘКЧЕЛЕК БУЛДЫРЫРГА

Авыл хуҗалыгы производствосы өчен квалификацияле механизатор кадрлар хәзерләү һәм алар белән эшләү гадәттән тыш әһәмиятле чара булып тора.

Техниканы үзләштергән кадрлар булмаганда һәм аларны булдыру өчен тиешенчә эшләмәгәндә югары иген уңышы өчен көрәшүнең уңышсыз чыгуы һәр кем өчен ачык нәрсә булырга тиеш. 1939 нчы елны трактор эшләренең планы хурлыклы рәвештә өзеклектә калуны (77,3 процент кына үтәлү) кадрлар белән начар эшләүнең дә нәтиҗәсе итеп карарга кирәк.

Шунлыктан, механизатор кадрлар хәзерләү эше сугышчан бурычларның берсе булып тора. Ләкин механизатор кадрлар хәзерләү эше Татарстанда гафу ителмәслек начар бара.

Турыдан-туры фактлардан башлыйк. 20 нче январьга булган мәглүматларга караганда, Татарстанда механизатор мәктәпләренә укучылар туплау планы бары тик 68,1 процент үтәлгән. Мәктәпләрдә һәм курсларда 9.715 кеше урнына 6.621 генә кеше укый. Совхозтрест системасында эш тагын да начар тора, монда механизатор кадрлар хәзерләү мәктәпләрендә 1.178 кеше урнына бары 593 кеше укый. (46 процент).

Бу уртача саннар. Аларны тикшереп карасак, аерым тармаклар өчен кирәк булган кадрларны хәзерләү эше бөтенләй үтәлмәү куркынычы астында торуны күрәбез. Мәсәлән, ЧТЗ—СГ—65 өчен тракторчылар хәзерләү мәктәпләрендә уку өчен 379 кеше урнына 85 кенә кеше (22,4 процент) кабул ителгән. ХТЗ тракторчылары мәктәпләрендә укучылар саны да бик аз (421 урнына 149 кеше). Ә газогенераторлы тракторларга кадрлар хәзерләү эше тагын да начар тора.

Механизатор кадрлар хәзерләү эшенең мондый хәлдә калуына Татнаркомзем һәм Совхозтрест җитәкчеләре, МТС, совхоз һәм механизация мәктәпләренең директорлары гаепле. 1 нче Май МТС ы директоры Юсупов, Акташ МТС ы директоры А. Б. Сурков, Кичү МТС ы директоры Мамзяков һәм Рождественский МТС ы директоры Галиуллин иптәшләр комбайнчылар һәм яңа маркадагы тракторлар өчен тракторчылар хәзерләү курсларына әлегә кадәр бер генә кеше дә җибәргәннәре юк.

Октябрь МТС ы директоры А. Г. Беляев иптәш тә комбайнчылар курсына 11 кеше урнына бары 3 кеше җибәргән. Ә иптәш Беляев кадрлар җитешмәү турында бөтенесенә караганда да күбрәк зарлана торган кеше.

Үткән елны тракторлар белән эшләү планын бары тик 40,7 процент кына үтәүче Зөя МТС ы да тракторчылар курсына 18 урнына 6 гына кеше һәм комбайнчылар курсына да 4 кенә кеше җибәргән. Бу МТС директоры иптәш З. Г. Галиуллин үткән елгы сабакларын әле һаман да искә алмый булса кирәк. Ул 1939 нчы елны комбайнчыларның һәм тракторчыларның хәзерлекләре йомшак булуны, планны үти алмауларын хәтерендә тотмый. Әйе, бездә әле җәй көне кадрлар җитешмәүдән зарланып йөрүче, ә кыш көне аларны хәзерләү турында уйлап та карамаучы хәсрәт җитәкчеләр бар. Иптәш Галиуллин әнә шундыйларның берсе.

Без мондый фактларны, кызганычка каршы, башка МТС ларда да очратабыз. Мәсәлән, Тат. Ходяш, Әлмәт, Яңа Чишмә, Биләр, Әлки, Юдино һ. б. МТС лар механизатор кадрлар мәктәпләренә, курсларына укучылар туплау планын үтәми киләләр.

Механизатор кадрлар хәзерләү планы Совхозтрест буенча да шул ук сәбәпләр аркасында үтәлми. „Красный Восток“ совхозы директоры Сайманов, политбүлек начальнигы Зиганшин, „Камское Устье“ совхозы директоры Лазарев, Киров исемендәге совхоз директоры Латыпов һәм политбүлек начальнигы Максудов иптәшләр механизатор кадрлары хәзерләү мәктәпләренә кешеләр җибәрмиләр, үзләрендәге курсларга да укучылар тупламыйлар. Кадрлар хәзерләүгә моннан да башбаштак карашның булуы мөмкинме?

Хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү бигрәк тә начар тора. МТС, совхоз җитәкчеләре һәм механизатор кадрлар хәзерләү мәктәпләре мөдирләре хатын-кызлардан кадрлар хәзерләүнең политик әһәмиятенә игтибар бирмиләр. Шуның нәтиҗәсендә, механизатор кадрлар хәзерләү мәктәпләрендәге составта хатын-кызлар бары тик 13 процент тәшкил итә. Ә Совхозтрест системасында ул 5—6 процент чамасыннан да узмый.

Бездә хатын-кызлардан механизатор кадрлар хәзерләү мәсьәләсендә сөйләнеп йөрү генә күп. Анда да, монда да резолюция, йөкләмәләр кабул ителә, зур нәрсәләр вәгъдә ителә. Ә эшкә килгәндә зур аермалык килеп чыга. Татарстан республикасы, әйтик, 1939 нчы елны МТС ларда 2.474 хатын-кызны производстводан аермыйча механизатор кадр итеп хәзерләү йөкләмәсен алган иде. Фактта исә бары 216 кеше хәзерләнде, яки план 8,7 процент кына үтәлде.

Бу хурлыклы нәтиҗә нәрсәдән килә? Татнаркомземның, Совхозтрестның алган йөкләмәләрне үтәү эшенә җидди карамауларыннан, МТС һәм совхозлар эшенә контроль ясамауларыннан килә. ВКП(б) һәм ВЛКСМ райкомнары да бу әһәмиятле бурычны үтәүдән читтә торалар. Хатын-кызлардан механизатор кадрларны хәзерләү зур политик эш булуны белә торып аңа игтибарсыз карыйлар.

Язгы чәчүгә чыгуга вакыт аз калып бара. Кадрлар хәзерләү эшен юлга салу, бу тармактагы эш планын тулысы белән үтәү өчен барлык чаралар күрелергә тиеш. Бер генә МТС ның да, бер генә совхозның да кадрлар хәзерләү планын үтәмәскә хакы юк. Авыл хуҗалыгындагы һәрбер катлаулы машина җитәрлек сандагы һәм югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин ителсен!

Механизатор кадрлар хәзерләү мәктәпләренә һәм курсларына укучылар алу планын һич сүзсез үтәү белән бергә, мәктәпләр эше өчен барлык шартларны булдырырга кирәк. Укырга кергән кеше, курстан тракторчы яки комбайнчы булмыйча чыкмасын!

Урыннарда исә бу курслар эшенә игтибар бирелми. Бөгелмә, Алабуга һәм Чаллыдагы мәктәпләрне тикшерү нәтиҗәсе 116 кешенең укуны бетерми китүен күрсәтте. Бөгелмәдә курсантлар торак белән тәэмин ителмәгәннәр, 2—3 ай буена стипендия бирелми килгән. Усадтагы комбайнчылар мәктәбенең бинасы җылытылмый һәм җыештырылмый. Торакларда умывальниклар юк, кайнаган су булмый. Курсантлар арасында политбеседалар, газета укулар алып барылмый. Стена газеталары чыгарылмый. Бу мәктәп Чыбыклыдагы комбайнчылар мәктәбе белән ярыша, ярыш договоры исә бер генә тапкыр да тикшерелгәне юк. Башлангыч партоешма (секретаре иптәш Гафаров) мәктәптә уку-укыту эшләренең, тәрбия эшләренең куелышын бер тапкыр да җыелышка куеп тикшергәне юк. Нәтиҗәдә, укырга йөреш проценты түбән, начар билгесе алучылар да байтак.

МТС һәм совхоз директорлары механизатор кадрлар хәзерләү эшен үз кулларына алырга тиешләр. Мәктәптә яки курста укып чыккан һәрбер иптәш яхшы тракторчы, комбайнчы булырга, политик белемле, уяу, сизгер булырга тиеш. Шуның өчен дә мәктәпләрне яхшы укытучылар белән тәэмин итү, уку-укыту программаларын тулысынча һәм яхшы сыйфатлы итеп үтәүне булдыру сугышчан бурыч булып тора.

Механизатор кадрлар хәзерләү эшен шулай итеп оештырырга кирәк ки, язгы чәчүгә кадәр кадрлар хәзерләү эшен тәмамларга, һәрбер МТСны һәм совхозны кирәк сандагы кадрлар белән тәэмин итәргә һәм 1940 нчы елның авыл хуҗалыгы эшләре планын тулысынча үтәү өчен большевистик кадрлар булдырырга кирәк.

Х. Хәбибуллин.

Ф. Вальшин.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ФИЗКУЛЬТУРНИКЛАР АРАСЫНДА

Казанның спорт җәмгыятләре арасында „Спартак“ җәмгыяте күренекле урынны алып килә. Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез флотының XXII еллыгына хәзерлек буенча „Спартак“ киң программа белән эшкә кереште. 15 нче январьда Осоавиахимның ату спорты буенча Бөтенсоюз ярышлары башланган иде. Бу ярышлар 15 нче февральгә кадәр дәвам итә. Анда Казан „Спартагының“ ике командасы катнаша.

Промкооперация системасындагы союзларның командалары арасында шашка ярышлары үткәрелә. Шашкачылар граната ыргыту һәм ату нормаларын башкарачаклар һәм командаларның теге яки бу урынны алулары шушы оборона төрләрен ничек үтәүләренә бәйләнгән булачак. 24 нче февральдә „Спартак“ның ату спорты буенча массовый ярышлары үткәрелә. Шулай ук бәйрәм көнендә чаңгыларда хәрбиләштерелгән поход оештырыла. Противогаз кигән хәлдә ирләр 5 километр, хатын-кызлар 3 километр үтәчәкләр.

Кызыл Армия көненә багышлап шәһәр күләмендә үткәрелә торган ярышларда да „Спартак“ актив рәвештә катнашачак.

АТУ ЯРЫШЛАРЫ

Кайбыч районында Кызыл Армия көненә ныклы хәзерлек алып барыла. Район үзәгендә оборона түгәрәкләре значкистлар хәзерлиләр.

Осоавиахимның Зур Русак, Рус Бәрлебашы, Уланово авылларындагы башлангыч оешмалары бәйрәмне значкистлар санын арттыру белән каршылау өчен көрәшәләр. 19 нчы февральдә район үзәгендә XXII еллыкка багышлап ату ярышлары үткәрелә.

Й. Фирушин.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ҖИҢҮЛӘРЕНӘ БАГЫШЛАНГАН КҮРГӘЗМӘ

Татарстанның фәнни көтепханәсе Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез флотының XXII еллыгына зур күргәзмә хәзерли. Күргәзмә „Ленин—Сталин партиясе—Эшче-Крестьян Кызыл Армиясен һәм Хәрби Диңгез Флотын оештыручы“, „Гражданнар сугышы чорында Кызыл Армиянең героик көрәше“, „СССР да социализмның җиңүе“ һәм „Илнең куәтен ныгыту“, „Капиталистик чолганыш“, „Кызыл Армия геройлары“, „Ватанны саклау—СССР гражданынның изге бурычы“ һәм башка бүлекләрдән тора. Анда Кызыл Армия турындагы фото-документлар, диаграммалар һәм әдәбият куела.

Күргәзмә көтепханәнең уку залында 17 нче февральдә ачыла.

ВАХИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КӨТЕПХАНӘДӘ

Сталин районының (Казан) Мулланур Вахитов исемендәге көтепханәсе данлыклы XXII еллык бәйрәмгә хәзерлек уңае белән, докладлар һәм беседалар үткәрү өчен кулланма материаллардан күргәзмә оештыра. Допризывниклар белән Кызыл Армия Йортына һәм иң актив укучылар белән Ленин исемендәге үзәк көтепханәгә экскурция ясалачак. 18 нче февральдә көтепханәдә әдәби кичә үткәреләчәк һәм лектор иптәш Воронкова тарафыннан „Матур әдәбиятта Кызыл Армия“ дигән темага лекция укылачак. Хәрби әдәбиятны күп укучы пенсионер Гисси һәм башка иптәшләрнең кичәдә чыгышлары булачак.

Көтепханәнең балалар бүлегендә дә Кызыл Армия көненә зур хәзерлек бара.

Бөек бәйрәмгә художникның бүләге

Татарстанның күренекле һәм карт художнигы Василий Кириллович Тимофеев орденлы республикабызның XX еллык юбилеенә зур полотнога матур итеп эшләнгән „Җирне мәңгелеккә файдалануга бирү“ дигән рәсем хәзерли. Художник Тимофеевның бу рәсеме колхоз төзелешенең зур җиңүен күрсәткән тарихи вакыйгане сурәтли. Художник үзенең рәсемендә Әтнә районы Олы Мәңгәр авылы колхозына җирдән мәңгелеккә файдалану актын тапшыру моментын күрсәтә.

Иптәш Тимофеев бу рәсем өстендә 4 елга якын эшләгән.

Пионерлар һәм Мәктәп Балалары Йортында

Пионерлар һәм Мәктәп Балалары Йортының түгәрәкләре республиканың данлыклы юбилеенә хәзерлек башладылар. Хор түгәрәге күп кенә җыр һәм марщлар өйрәнә. Бию түгәрәге украин, белорус, татар биюләрен хәзерли. Сынлы сәнгат түгәрәге „бәхетле балачак“ дигән рәсем хәзерли.

Татарстан республикасы тарафыннан 20 ел эчендә ирешелгән уңышлар турында мәктәп балалары арасында тәртипле рәвештә популяр беседалар алып барылачак.

Яхшы эшләүче саклык кассалары

Чистай районында 1939 нчы елда 4 саклык кассасы ачылган иде. Бу кассалар кыска гына вакыт эчендә шактый зур уңышларга ирештеләр.

Судоремонт саклык кассасы еллык планны 305,8 процент, С. Шанталы авылы саклык кассасы 105 процент, Тат. Талкыш—140 процент, Булдырь—133 процент һәм Кубасс саклык кассасы 132 процент итеп үтәделәр.

Колхозчылар заемга взнос кертүне срогыннан элек тәмамлыйлар

Татарстан колхозчылары Өченче Бишьеллык (икенче ел чыгарылышы) Заемына 16 миллион 232 мең сум күләмендә язылганнар иде.

Районнарның күпчелегендә заемга взнос кертү срогыннан элек тәмамлана. Чепья районы колхозчылары взнос кертүне тулысынча тәмамладылар. Тымытык районы колхозчылары взнос кертү планын 99,6 процент, Мөслим районы колхозчылары—95,6 процент, Ютазы, Кызыл Юл һәм Калинин районы колхозчылары—90 процент үтәделәр.

Татарстан колхозчылары 1 нче февральгә барлыгы 11 миллион 258 мең сум взнос керттеләр. Бу сан подписка сумасының 69,3 процентын тәшкил итә. (ТатТАСС).

Терлекләр саны арта

Чистай районында 1931 нче елда фермалардагы мөгезле эре терлекләр саны 1.009 баш иде, 1939 нчы елда терлекләр саны 2.182 башка җитте. Шул ук вакыт эчендә сарыклар саны 3.600 баштан 7.725 башка, дуңгызлар саны 377 баштан 3.575 башка җитте.



РӘСЕМДӘ: Казан пехота училищесе отличниклары (сулдан) Бутеров, Селезенов, Ганчаров, Лонов һәм Прощин иптәшләр пулемет частьләрен өйрәнәләр.

М. Солтанов фотосы.

Совет кинематографиясенең XX еллыгы

15 нче февральдә совет кинематографиясенең төзелүенә XX ел тула. Бөтен совет халкы бу гүзәл датаны культура үсешенең яңа җиңүе итеп билгеләп үтәчәк.

Татарстан республикасында да кино челтәре бик нык үсте. 1920 нче елда Татарстанда барлыгы биш кино-театр булса, 1940 нчы елда аларның саны шәһәрдә 8 гә җитте. Район үзәкләрендә 62 урында стационар кино-театрлар ачылды. Республикабызның 40 колхозында колхоз кино-театрлары эшли башлады. Болар өстенә тавышлы 59 күчмә кино булдырылды.

Татарстан Кинофикация Тресты юбилей уңае белән орденлы Татарстан республикасында кино челтәренең үсешен күрсәтү, киноны массага тагын да якынайту буенча күп кенә чаралар билгеләде.

15 нче февральгә кадәр Казандагы „Электро“ һәм „Чаткы“ кино-театрларында Совет киносының идея-политик һәм художество ягыннан яхшы эшләнгән үрнәкләреннән кино-фестиваль башланды. Ул 15 нче февральгә кадәр дәвам итә. Фестиваль вактында тавышлы һәм тавышсыз картиналар күрсәтелә.

Кино механиклар һәм кино работниклары арасында социалистик ярыш тагын да җәелдерелде. Алдынгы кино-театрлардан „Электро“ һәм Кукмара кино-театры кызыл байрак өчен көрәшәләр. Барлык кино-театрларда данлыклы еллыкка багышланган күргәзмәләр төзелә һәм докладлар белән кичәләр үткәрелә. 15 нче февральдә Казанда партия, совет һәм профсоюз вәкилләре катнашы белән кино активының тантаналы җыелышы үткәрелә.

Татарстанның район үзәкләрендәге һәм колхозлардагы стационар кино-театрларга совет кино сәнгатенең иң яхшы фильмнәре җибәрелә.

Союзкинохрониканың Казан студиясе Татарстанда кино челтәренең үсешен күрсәткән махсус кино-журнал чыгара.

Р. Н.

Зур темаларга таба

Шагыйрь Әхмәт Фәйзи иптәш „Г. Тукай“ пьесасы белән татар совет драматургиясендә тарихи типларны гәүдәләндерүдә беренче булып уңышлы адым атлаган иде.

Ишмурат һәм Фәтхуллин иптәшләр тагын да җаваплырак эшкә зур кыюлык белән керештеләр. Алар татар совет сәнгатендә бөек Ленин образын күрсәтүгә матур гына омтылыш ясадылар.

Татарстан Совет Язучыларының Г. Тукай исемендәге кабинетында Ишмурат һәм Фәтхуллин иптәшләрнең „Ялкынлы яшлек“ исемле пьесасы укылды. Бу ике драматург Владимир Ильичнең Казан университетына укырга керүен, андагы маглүм сходкада беренче революцион чыгыш ясаганнан соң, Лениннең Кокушкино авылына сөргенгә җибәрелгән вактын якътыртуны бурыч итеп куйганнар. Алар үзләренең бурычларын шактый матур итеп башкарганнар дияргә мөмкин. Студент Ильич безнең күз алдыбызга тирән белемле, зур культуралы, һәр нәрсәгә дә тиз ориентация ясый ала торган кеше булып килеп баса.

Шуның белән бергә, пьесада шактый гына кимчелекләр дә сизелә. Ләкин аларны бик җиңел төзәтергә мөмкин. Пьесада катнашучыларның саны бик күп (35 кә җитә), аларның шактый өлешен кыскартканда пьесага һич зарар килмәячәк. Бөек гуманист Владимир Ильичнең кешелек черталары да җитәрлек дәрәҗәдә бирелмәгән. Пьесадагы кайбер типлар тиешле дәрәҗәдә эшләнмәгәннәр. Мәсәлән, Наташа, Алкин һәм башкалар Алкинның социаль йөзе ачылмаган.

Пьсаны тикшерү җыелышында 35 ләп кеше катнашты. Алар, пьесаны яхшырту теләгеннән чыгып, күп кенә кыйммәтле фикерләр әйтеп үттеләр һәм пьесага зур бәя бирделәр.

А. Алиш.

Шәриф Камал юбилее алдыннан

Казан Укытучылар Йорты татар совет язучысы Шәриф Камалның 30 еллык юбилеенә хәзерләнә. Татар драма түгәрәге (җитәкчесе Татар Дәүләт Академия Театры артисты Хабибов) юбилей көннәрендә сәхнәгә кую өчен язучының „Хаҗи әфәнде өйләнә“ дигән комедиясен хәзерли.

Көтепханә Шәриф Камал әсәрләреннән әдәбият күргәзмәсе оештыра. Атаклы язучы—Казан Шәһәр Советы депутаты Ш. Камал белән очрашу кичәсе үткәреләчәк.

Хәрби физкультура эшләре киң җәелде

Чистай районы уку йортларында, мәктәпләрендә һәм колхозларында хәрби физкультура эшләрендә актив катнашып эшләүче комсомолец һәм союздан тыш яшләр арасында значкистлар саны артканнан арта бара. Мәсәлән, фельдшер-акушерлык мәктәбе янындагы комсомол оешмасы (секретаре Граханцев) инициативасы белән соңгы вакытларда 150 кеше төрле оборона значекларына нормалар тапшырдылар.

2 нче номерлы урта мәктәптә 289 кеше, педагогия рабфагында 100 кеше һәм фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбендә 20 кеше „Ворошиловча атучы“ значегына норма тапшырдылар. Тат. Багана, Мөслим, Булдырь һәм Шанталы авылларында да значкистлар саны арта бара.

К. Исламов.

Колхоз базарларында авыл хуҗалыгы товарлары сату

Чистай районы колхоз базарларында авыл хуҗалыгы товарларын сату елдан-ел арта. 1938 нче елны колхозчылар 2.713 тонна икмәк, 405 тонна ит, 1.048 тонна яшелчә, 269.435 литр сөт, 140.660 данә йомырка, 49 тонна каймак, 3.320 баш каз, тавык һәм үрдәк сатканнар. 1939 нчы елның 9 аенда гына да 1.535 тонна икмәк, 377 тонна ит, 532 тонна яшелчә, 186.750 литр сөт, 313.500 данә йомырка, 46 тонна каймак, 3.183 баш каз, тавык һәм үрдәк сатылган.

СУДТА

Казан шәһәре, Киров районының 2 нче участкы халык суды 7 нче февральдә агалы-энеле Сагдеевләрнең эшен карады. Алар спекуляция ясау теләге белән үзләренең квартираларына 800 килограмм он, 90 килограмм ярма, 150 килограмм арпа, 25 килограмм кара борыч һәм башка продуктлар җыйганнар.

Халык суды Бәдри Сагдеевне 5 елга иркеннән мәхрүм итәргә, Билал Сагдеевне 500 сум штраф түләргә хөкем итте.

БЕЛДЕРҮ

13 нче февраль, кич 6 сәгатьтә Казан Дәүләт Университетының Актовый залында, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби-Диңгез Флотының XXII еллыгы турында докладчылар өчен инструктив доклад үткәрелә. Докладчы иптәш Гостев. Билетлар ВКП(б) райкомнары аркылы таратыла. *ВКП(б) Шәһәр Комитеты.*

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ОБОРОНА КӨННӘРЕ

Ленин районындагы (Казан) предприятиеләрдә зур хәзерлек белән үткәрелгән оборона көннәре яхшы нәтиҗәләр бирде. Шушы көннәрдә генә 37 нче номерлы мәктәптә оборона көне үткәрелде. 170 укучы, противогаз кигән хәлдә, бер сәгат дәрестә булдылар, Ворошиловча яш атучы, ПВХО һәм башка түгәрәкләр бу көннәрдә аеруча яхшы эшләделәр. Мәктәп директоры иптәш Никифоров противогаз кигән хәлдә, 3 сәгать дәрес үткәрде.

2 нче номерлы теплоэлектроцентральда Осоавиахим оешмасы „Деникинны тар-мар итү планы“ темасына лекция үткәрде. Лекциягә 200 дән артык кеше катнашты. фото-желатен заводында агитаторлар халыкара хәл турындагы темага беседалар үткәрделәр, аларда 200 гә якын кеше катнашты. „20 лет Октября“ артеле янындагы Осоавиахим оешмасы да соңгы вакытта эшен шактый яхшыртты. 1939 нчы елның III нче кварталында Осоавиахим членнарының саны 30 булса, 1940 нчы елның январенда инде бу сан 92 гә җитте. ПВХО һәм Ворошиловча атучылар түгәрәкләре оештырылды. 1939 нчы елның декабрендә Ворошиловча атучы знаскистлар итеп 30 кеше хәзерләнде һәм ПВХО значегына 30 кеше норма тапшырды.

Шуның белән бергә оборона көннәренә һәм массовый оборона эшләренә әһәмият бирмәүче кайбер предприятиеләр дә бар. 5 нче совхозның партия оешмасы массовый оборона эше турында берничә тапкырлар карар чыгарды. Ләкин анда әле һаман да бер генә түгәрәк тә оештырылмаган һәм оборона көне бер тапкыр да үткәрелмәгән.

А. Овчинников.

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН—ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЯРЫШТА ӨСТЕН ЧЫГАРБЫЗ

Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзекләндерүнең хуҗалык һәм политик әһәмияте гаят зур. Бу эштә ферганәчеләр тәҗрибәсен куллану алда торган бурычларны уңышлы итеп хәл итүгә юнәлтелгән. Төзек юллар өчен көрәш бүгенге көннең мактаулы бурычы.

Безнең Әлмәт районының 260 нчы номерлы юл төзү участкысының 3 нче дистанциясе 38 километрга сузылган һәм шул территориягә хезмәт күрсәтә. Участкыбыздагы юлларның яхшы сыйфатлы булуы белән без бик урынлы мактанабыз. Моның ачык билгесе итеп, 3 ел инде, участкының күчмә кызыл байрагын үз кулыбызда тотабыз.

Шулай да, безне бу уңышлар гына тынычландырмый. Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчылары мөраҗәгатенә практик эш белән җавап бирәбез. Төзек юллар өчен булган ярышта өстен чыгуыбызга нык ышанабыз.

Дөрес, алда торган бурычлар зур һәм катлаулы. Ләкин алар безне куркытмый. Без быел 11 километр юлга капиталь ремонт, 27 километр юлга агымдагы ремонт үткәрергә, пассажирлар өчен берничә урында культуралы павильоннар төзергә, бу эшләрне башкару өчен эш объектларына 3.200 кубометрдан артык төзү материаллары ташырга тиешбез.

Район колхозлары алда торган бурычларны үтәү өчен намус белән көрәшәләр. Грави ташу эшен 1 нче мартка, юлларны ремонтлау эшен 1 нче майга төгәлләячәкбез. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Алдынгы колхозларның үрнәк эш тәҗрибәләре моңа тулы ышаныч бирә.

Мәсәлән, „Бакчасарай“, „Кызыл Армеец“ колхозлары грави хәзерләү һәм ташу планын үтәделәр дә инде. Ремонтчы иптәш Шәймәрдәнев участкысында бу эш якын көннәрдә тәмамлана. Колхозчылар юл төзелешендә зур күтәренкелек белән эшлиләр. Сталин исемендәге колхозның юл төзелешендә эшләүче стахановчылары Нигмәтдинов, Сафин һәм башка иптәшләр үзләренең көнлек нормаларын 200—250 процент итеп үтиләр.

Ләкин менә Әлмәт лесопункты (мөдире иптәш Габдырахманов) һәм шулай ук 260 нчы номерлы юл төзелеше участкысы җитәкчеләре (начальник урынбасары иптәш Иванов) массаның бу активлыгын читләтеп үтәләр. Алар безнең практик эшебезгә җитәрлек дәрәҗәдә булышлык күрсәтмиләр. Мәсәлән, лесопункт безгә договор буенча хәзерләргә тиешле булган 100 кубометр агачның хәзергәчә бер кубометрын да хәзерләмәгән әле. Бу агачның кайчан булачагы да билгеле түгел. Шулай ук 260 нчы участкы җитәкчеләре дә Ферганә тәҗрибәсен юллар төзелешенә күчерү хәрәкәтен җәелдерү буенча бер нәрсә дә эшләмиләр, „бу турыда ишеткәнебез юк“ дип акланырга маташалар.

Г. Шәфиков.

260 нчы участкының 3 нче дистанция мастеры.

Татарстан АССР Җинел Промышленность Халык Комиссариаты И. В. Сталин исемендәге ФЗУ мәктәбенең укыту-производство бүлеге мөдире, ТАССР Җинел Промышленность Наркоматының метод секциясе мөдире, Казан Шәһәр Советы депутаты

СЕРГЕЙ АЛЕКСАНДРОВИЧ НИКОЛАЕВ

ның шушы ел, 8 нче февральдә вакытсыз үлүе уңае белән тирән кайгы һәм аның семьясенә кайгы уртаклашу белдерә.
Татнаркомвестпром.
259—1

СССР Госпланының Счет Работниклары Хәзерләү управлениесе
ТАТАРСТАН УКЫТУ-КУРСЛАР КОМБИНАТЫ
ПРОИЗВОДСТВОДАН АЕРМЫЙЧА УКЫТЫП
счет работникләры хәзерләү һәм счет работник-
—ларының квалификацияләрен күтәрү буенча—
КУРСЛАР АЧА:
1. Баш һәм өлкән бухгалтерларның һәм аларның урынбасарларының квалификацияләрен күтәрү группасы. Уку срогы 8 ай.
2. Бухгалтерларның квалификацияләрен күтәрү группасы. Уку срогы 6 ай.
3. Бухгалтерлар хәзерләү группасы. Уку срогы, каникул вактын исәпләмичә, 13 ай.
4. Хисапчылар хәзерләү группасы. Уку срогы 10 ай. Хисапчылар хәзерләү буенча татарлар өчен махсус группа оештырыла.
5. Уртадан түбән белемле (5—6 класс тәгәлләгән) кешеләр өчен хәзерлек группасы ачыла. Уку срогы 5 ай.
Барлык группаларда укулар кичке сәгатләрдә, айга 15 тапкыр үткәрелә.
Гаризалар һәр көн кич 5 сәгаттән 10 га кадәр алына. Казан, Островский урамы, 22, 11 нче мәктәп.
251—2—1

„ЗАГОТЗЕРНО“
ның Казан базасы
Спартак урамындагы
42 нче йортка
(элек „Заготзерно“ның Казан бүлеге урнашкан йортка)
КҮЧТЕ
Телефоннар: 33—95 һәм 27—19.
176—2—2

Москвадан килгән инженерларны урнаштыру өчен, төрле срокларга
БҮЛМӘЛӘР КИРӘК
Түләү килешү буенча. Бауман урамы, 70. Телефон 44—05. Новицкий.
177—2—2

РСФСР Сәүдә Халык Комиссариатының Казандагы өлкәара базасы
„РОССНАБТОРГ“
1940 нчы ел, 1 нче январьдан
„РОСЗАГОТСНАБТОРГ“
дип яңадан исемләнде.
240—2—1

Татар Дәүләт Опера театры түбәтәйләр, чулпылар, күн кәвешләр, каракульдән эшләнгән татар бүрекләре, ирләр һәм хатын-кызлар өчен эшләнгән кунычсыз киез итекләр һәм хатын-кызлар өчен эшләнгән чигүле читекләр сатып ала. Казан, Зур Галактионов урамы, 13. Телефон 29—04.
250—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче февральдә көндез 12 сәгатьтә һәм кич
ТУКАЙ
Талоннар: көндез 113, кич 114.
13 һәм 14 нче февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ“
Талоннар: 115 һәм 116.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН һәм һәр көн
Тулысынча яңа программа
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты, орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән.
12 нче февральдә көндез 12 сәгатьтә
М. ЗОЛЛО катнашы белән зур цирк уены.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Телефоннар: 30—78 һәм 29—04
Бүген, 11 нче февральдә
Мединститут коллективы өчен,
ЯБЫК СПЕКТАКЛЬ
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Талоннар белән кертелми.

А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ
бөек пролетар язучы Горькийның әсәрләрен һәм язучы турында критик әдәбият
САТЫП АЛА
Казан, Кече Галактионов урамы, 24.
255—2—1

Казан Ветеринария техникумы студентларын урнаштыру өчен
БҮЛМӘЛӘР ҺӘМ ПОЧМАК
УРЫННАР КИРӘК
Тәкъдимнәр өчен адрес: Телеграф тыкрыгы, 6-9. Телефон 24—44.
214—3—2

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
11 нче февральдә
РЕВИЗОР
Талон 98.
12 нче февральдә көндез
МАСКАРАД (талон 20)
кич
КУРКЫНЫЧЛЫ БОРЫЛЫШ
(талон 99).
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ЗУР ТЕАТР ФИЛИАЛЫ
(Киров районы Культура сарае)
11 нче февральдә, шулай ук 12 нче февральдә көндез һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар: 11 ндә 46 һәм 47, 12 ндә көндез 49, 50 һәм кич 51, 52.
Спектакльләр көндез 12 сәгатьтә, кич 8 дә башлана.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да,	ФУТЛЯРДАГЫ КЕШЕ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4. 6, 8 һәм 10 да	КОМСОМОЛЬСК
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да.	11 нче ИЮЛЬ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	КАЙНАР КӨННӘР
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ЗАПОРОЖЕЦ ЗА ДУНАЕМ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	УКЫТУЧЫ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 713 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 560.